РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**21.10.2022** Кукмара ш. **№ 556**

«Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына (балалар бакчалары) гариза бирү, балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» муниципаль хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау һәм «Мәгариф өлкәсендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2021 елның 22 июнендәге 422 номерлы Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты карарының кайбер нигезләмәләрен куллану мәсьәләләре хакында» Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2021 елның 21 декабрендәге 753 номерлы карарына үзгәреш кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә **карар бирәм:**

1. «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына (балалар бакчалары) гариза бирү, балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» муниципаль хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау һәм «Мәгариф өлкәсендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2021 елның 22 июнендәге 422 номерлы Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты

карарының кайбер нигезләмәләрен куллану мәсьәләләре хакында» Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2021 елның 21 декабрендәге 753 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына (балалар бакчалары) гариза бирү, балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» муниципаль хезмәте күрсәтүнең административ регламентын әлеге кararга кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгълүмати-коммуникацион технологияләрне үстерү бүлегенә әлеге карарны «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында http://kukmor.tatarstan.ru адресы буенча урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары – Мәгариф идарәсе башлыгы И.И. Әхмәдуллинга йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А.Х. Гарифуллин**

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 21.10.2022 елгы 556 номерлы карарына кушымта

# Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының «Мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм җибәрү» муниципаль хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## Гомуми нигезләмәләр

### Административ регламентны җайга салу предметы

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының «Мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм җибәрү» муниципаль хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (алга таба – Административ регламент) муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфатын һәм үтемлелеген арттыру максатларында эшләнгән, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү оешмаларына балаларны исәпкә алу һәм җибәрү вәкаләтләрен тормышка ашырганда гамәлләр (административ процедуралар) стандартын, срокларын һәм эзлеклелеген билгели. Әлеге Административ регламент «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 67 статьясындагы 1 өлешенең 6 пункты, 9 статьясындагы 2 өлеше, 4.1 өлеше нигезендә барлыкка килгән мөнәсәбәтләрне җайга сала.

### Гариза бирүчеләр даирәсе

1.1. Муниципаль хезмәттән файдаланучы гариза бирүче – баланың ата-анасы (законлы вәкиле) (алга таба – гариза бирүче).

1.2. «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) Бердәм порталы» (алга таба – ЕПГУ) (https://www.gosuslugi.ru/) һәм /яки Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) төбәк порталы (алга таба – РПГУ) федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша муниципаль хезмәттән файдаланучы гариза бирүче булып, баланың «Электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада Бердәм идентификация һәм аутентификация системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба – ЕСИА) теркәлү процедурасын тәгәлләгән ата-анасы (законлы вәкил) тора.

### Муниципаль хезмәт күрсәтү турында мәгълүмат бирү тәртибенә таләпләр

1.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат бирү түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

1) гариза бирүчене «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәгариф идарәсе» муниципаль учреждениесендә (алга таба – Вәкаләтле орган) шәхсән кабул иткәндә турыдан-туры яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә (алга таба – күпфункцияле үзәк), күпфункцияле үзәк һәм Вәкаләтле орган арасында төзелгән килешү нигезендә.

2) телефон аша Вәкаләтле органда яки күпфункцияле үзәктә;

3) язмача, шул исәптән электрон почта, гомуми кулланыштагы почта элемтәсе (алга таба – почта элемтәсе) аша;

4) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә ачык һәм һәркемгә ачык мәгълүмат урнаштыру юлы белән:

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) Бердәм порталы»нда һәм /яки «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) төбәк порталы»нда

Вәкаләтле органның рәсми сайтында *http://edu.tatar.ru/kukmor/otdel.*

5) Вәкаләтле орган яки күпфункцияле үзәкнең мәгълүмат стендларында мәгълүмат урнаштыру аша.

1.4. Мәгълүмат бирү түбәндәгеләргә кагылышлы мәсьәләләр буенча алып барыла:

муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза бирү ысуллары;

муниципаль хезмәт күрсәтү өчен мөрәҗәгать итәргә кирәкле Вәкаләтле орган һәм күпфункцияле үзәкләрнең адреслары;

Вәкаләтле орган (Вәкаләтле органның структур бүлекчәләре) һәм күпфункцияле үзәкләр эше турында белешмә мәгълүмат;

муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр исемлегенә кертелгән хезмәтләр;

муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары;

муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гаризаны карау барышы һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмәләр алу тәртибе;

вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) һәм муниципаль хезмәт күрсәткәндә алар тарафыннан кабул ителә торган карарларга карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе.

муниципаль хезмәт күрсәтү һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр исемлегенә кертелгән хезмәтләр мәсьәләләре буенча мәгълүмат алу түләүсез башкарыла;

1.5. гариза бирүче телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша) Вәкаләтле органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәкнең консультация бирүче хезмәткәре, кызыксынган сораулар буенча мөрәҗәгать итүчеләргә җентекләп һәм әдәпле (корректно) итеп мәгълүмат бирә.

Телефоннан шалтыратуга җавап гариза бирүче чакырган органның исеме, телефон шалтыратуын кабул иткән белгечнең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (соңгысы булган очракта) һәм вазыйфасы турындагы мәгълүматтан башланырга тиеш.

Әгәр дә Вәкаләтле органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк хезмәткәре мөстәкыйль рәвештә җавап бирә алмаса, телефоннан шалтырату башка вазыйфаи затка адресланырга (күчерелергә) яки мөрәҗәгать иткән кешегә кирәкле мәгълүматны алу өчен телефон номеры хәбәр ителергә тиеш.

Әгәр дә җавап әзерләү озак вакыт таләп итсә, ул гариза бирүчегә алдагы вариантларның берсен тәкъдим итә:

мөрәҗәгатьне язма формада бәян итәргә һәм Вәкаләтле органның, күпфункцияле үзәкнең электрон почтасына яки почта элемтәсе аша җибәрергә;

консультация өчен бүтән вакыт билгеләргә;

шәхсән килергә.

Вәкаләтле органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк хезмәткәре муниципаль хезмәт күрсәтүнең стандарт процедуралары һәм шартлары чикләреннән чыгып, һәм кабул ителә торган карарга турыдан-туры яисә читләтеп йогынты ясый торган мәгълүмат бирүне гамәлгә ашырырга хокуксыз.

Телефон аша хәбәр итүнең дәвамлылыгы 10 минуттан артмаска тиеш.

Мәгълүмат бирү гражданнарны кабул итү графигы нигезендә башкарыла.

1.6. Язмача мөрәҗәгать буенча Вәкаләтле органның муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк хезмәткәре гражданга әлеге Административ регламентның 1.4 пунктында күрсәтелгән мәсьәләләр буенча мәгълүматларны язмача җентекләп «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә аңлатып бирә.

1.7. «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) Бердәм порталы»нда Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 24 октябрендәге 861 номерлы карары белән расланган «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасы турында нигезләмәдә каралган белешмәләр урнаштырыла.

Муниципаль хезмәт күрсәтү сроклары һәм тәртибе һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар турындагы мәгълүматтан файдалану гариза

бирүче тарафыннан нинди дә булса таләпләрне үтәмичә, шул исәптән программа тәэминатының хокук иясе белән гариза бирүченең техник чараларына урнаштыру гариза бирүчедән түләү алуны, аны теркәү яки авторизацияләүне, яки аларга шәхси мәгълүматлар бирүне күздә тота торган лицензия яисә башка килешү төзүне таләп итә торган программа тәэминатыннан файдаланмыйча, гамәлгә ашырыла.

1.8. Вәкаләтле органның рәсми сайтында, муниципаль хезмәт күрсәтү һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү урыннарында һәм күпфункцияле үзәктә стендларда түбәндәге белешмә мәгълүмат урнаштырыла:

Вәкаләтле орган һәм аның муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы структур бүлекчәләренең, шулай ук күпфункцияле үзәкләрнең урнашу урыны һәм эш графигы турында;

Вәкаләтле органның муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы структур бүлекчәләренең, шулай ук күпфункцияле үзәкләрнең белешмә телефоннары, шул исәптән автоинформаторның телефон номеры (булган очракта);

Вәкаләтле органның рәсми сайт, шулай ук «Интернет» мәгълүмати телекоммуникация челтәрендә электрон почта һәм (яки) кире элемтә формасы адресы.

1.9. Вәкаләтле органның көтү залларында муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибен көйләүче норматив хокукый актлар , шул исәптән гариза бирүче таләбе буенча аңа танышу өчен бирелә торган Административ регламент урнаштырыла.

1.10. Күпфункцияле үзәк бинасында муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турындагы мәгълүматны урнаштыру, Административ регламентта билгеләнгән мәгълүматка карата таләпләрне исәпкә алып, күпфункцияле үзәк һәм Вәкаләтле орган арасында төзелгән килешү нигезендә гамәлгә ашырыла.

1.11. Муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гаризаны һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен карау барышы турында мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан ЕПГУ һәм/яисә РПГУда шәхси кабинетында, шулай ук Вәкаләтле органның тиешле структур бүлекчәсендә, күпфункцияле үзәкләрдә гариза бирүче шәхсән, телефон аша, электрон почта яки почта элемтәсе аша мөрәҗәгать иткәндә алынырга мөмкин.

## II. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

### Муниципаль хезмәт күрсәтү атамасы

**2.1. «Мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм җибәрү» муниципаль хезмәте.**

### Муниципаль хезмәт күрсәтүче дәүләт хакимияте органы, җирле үзидарә органы (оешма) атамасы

2.2. Муниципаль хезмәт «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты Мәгариф идарәсе» муниципаль учреждениесе Вәкаләтле органы тарафыннан күрсәтелә.

«Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты Мәгариф идарәсе» муниципаль учреждениесенең урнашу урыны: Татарстан Республикасы, Кукмара ш., Эшчеләр тыкрыгы ур., 7.

«Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты Мәгариф идарәсе» МУ нең эш графигы: дүшәмбе - җомга, 8 сәгать 00 минуттан 17 сәгать 00 минутка кадәр, төшке ашка тәнәфес 12.00-13.00

«Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» МУ нең белешмә өчен телефоннары: кабул итү бүлмәсе 8(84364) 2-70-68, «Электрон балалар бакчасы» автоматлаштырылган мәгълүмат системасы өчен җаваплы 8(84364)2-70-41.

2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтүдә 10 нчы кушымтада бирелгән оешмалар катнашалар

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә Вәкаләтле орган түбәндәгеләр белән хезмәттәшлек итә:

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы;

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы үстерү, мәгълүмати технологияләр һәм элемтә министрлыгы;

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы

2.4. Вәкаләтле органга муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлегенә кертелгән хезмәтләрдән тыш, муниципаль хезмәт күрсәтүдән файдалану өчен кирәкле һәм башка дәүләт органнарына һәм оешмаларга мөрәҗәгать итү белән бәйле гамәлләрне, шул исәптән килештерүләрне башкаруны таләп итү тыела.

**Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау**

2.5. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора: муниципаль белем бирү оешмасында урын бирүгә мохтаҗларны исәпкә кую (арадаш нәтиҗә) һәм муниципаль белем бирү оешмасына юллама (төп нәтиҗә).

2.5.1. Әлеге Административ регламентка 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендәге форма буенча арадаш нәтиҗә өлешендә муниципаль хезмәт күрсәтү турында карар.

2.5.2. Әлеге Административ регламентка 3 нче кушымта һәм 4 нче кушымта нигезендәге форма буенча төп нәтиҗә өлешендә муниципаль хезмәт күрсәтү турында карар.

2.5.3. Әлеге Административ регламентка 5 нче кушымта һәм 6 нчы кушымта нигезендәге форма буенча арадаш нәтиҗә – исәпкә кую өлешендә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар

**Муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү кирәклеген дә исәпкә алып, муниципаль хезмәт күрсәтү вакыты, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору вакыты, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып торган документларны тапшыру (җибәрү) вакыты**

2.6. Вәкаләтле орган гаризаны һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны Вәкаләтле органда теркәгәннән соң 7 эш көне эчендә гариза бирүчегә гаризада күрсәтелгән ысул белән яисә, электрон рәвештә гариза биргән очракта, мәгълүматны ЕПГУ һәм/яисә РПГУда шәхси кабинетына җибәрү юлы белән Административ регламентның 2.5.1 яки 2.5.3 пунктларында күрсәтелгән нәтиҗәләрне җибәрә.

Вәкаләтле орган, гаризада күрсәтелгән тиешле кабул итү көнен исәпкә алып, муниципаль оешмада урын бирү турындагы документны раслаганнан соң 1 көн эчендә Административ регламентның 2.5.2 пунктында күрсәтелгән нәтиҗәне гариза бирүчегә җибәрә.

**Муниципаль хезмәт күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар**

2.7. Муниципаль хезмәт күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеге (аларның реквизитларын һәм рәсми бастырып чыгару чыганакларын күрсәтеп) «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасында, ЕПГУ һәм/яисә РПГУның тиешле бүлекләрендә, «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты Мәгариф идарәсе» муниципаль учреждениесенең рәсми сайтында урнаштырыла

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Мәктәпкәчә белем бирү программалары буенча укуга кабул итү тәртибен раслау турында» Россия Мәгариф министрлыгының 2020 елның 15 маендагы 236 номерлы боерыгы;

«Мәктәпкәчә белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы бер оешмадан укучыларны тиешле дәрәҗәдәге һәм юнәлештәге белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы башка оешмаларга күчерүне гамәлгә ашыру тәртибен һәм шартларын раслау турында» Россия Мәгариф министрлыгының 2015 елның 28 декабрендәге 1527 номерлы боерыгы (ата-ана (законлы вәкил) инициативасы буенча дәүләт яисә муниципаль белем бирү оешмасына күчерү өлешендә);

«Төп гомуми белем бирү программалары –мәктәпкәчә белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» Россия Мәгариф министрлыгының 2020 елның 31

июлендәге 373 номерлы боерыгы (аерым төркемнәрдә яки аерым белем бирү оешмаларында балалар саны өлешендә);

«Электрон балалар бакчасы» автоматлаштырылган мәгълүмат системасын формалаштыру һәм алып бару тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 21 ноябрендәге 1039 номерлы карары;

«Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә территорияләрне беркетү турында» Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты карары.

Муниципаль хезмәтләрне **чираттан тыш (беренче чиратта)** күрсәтүгә Федераль законнарда каралган хокук өлешендә:

«Россия Федерациясе прокуратурасы турында» 1992 елның 17 гыйнварындагы 2202-1 номерлы Россия Федерациясе Законы;

«Россия Федерациясендә судьялар статусы турында» 1992 елның 26 июнендәге 3132-1 номерлы Россия Федерациясе Законы;

«Россия Федерациясе Тикшерү комитеты турында» 2010 елның 28 декабрендәге 403-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Хәрби хезмәткәрләр статусы турында» 1998 елның 27 маендагы 76-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Полиция турында» 2011 елның 7 февралендәге 3-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Кайбер федераль башкарма хакимият органнары хезмәткәрләренә социаль гарантияләр һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2012 елның 30 декабрендәге 283-ФЗ номерлы Федераль закон; «Көньяк Осетия һәм Абхазия территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарының иминлеген тәэмин итү һәм яклау бурычларын үтәүдә катнашучы хәрби хезмәткәрләрне һәм федераль башкарма хакимият органнары хезмәткәрләрен социаль яклауны көчәйтү буенча өстәмә чаралар турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2008 елның 12 августындагы 587 номерлы карары; «Террорчылыкка каршы операцияләрдә катнашучы һәм Россия Федерациясенең Төньяк Кавказ төбәге территориясендә хокук тәртибен һәм иҗтимагый иминлекне тәэмин итүче хәрби хезмәткәрләргә һәм федераль башкарма хакимият органнары хезмәткәрләренә өстәмә гарантияләр һәм компенсацияләр турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2004 елның 09 февралендәге 65 номерлы карары;

«Дагыстан Республикасы территориясендә террорчылыкка каршы көрәштә турыдан-туры катнашкан һәм һәлак булган (хәбәрсез югалган), вафат булган, хезмәт бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә инвалид булган хәрби хезмәткәрләр һәм эчке эшләр органнары, янгынга каршы дәүләт хезмәте, җинаять-үтәү системасы хезмәткәрләренең гаилә әгъзаларын социаль яклау буенча өстәмә чаралар турында» 1999 елның 25 августындагы 936 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары.

«Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнарны социаль яклау турында» 1991 елның 15 маендагы 1244-1 номерлы Россия Федерациясе Законы;

«Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнарны социаль яклау турында» РСФСР Законының гамәлдә булуын махсус аеручы риск бүлекчәләреннән гражданнарга тарату хакында»1991 елның 27 декабрендәге 2123-1 номерлы Россия Федерациясе Югары Советы карары;

«Гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү чаралары турында» Россия Федерациясе Президентының 1992 елның 5 маендагы 431 номерлы Указы;

«Инвалидларга дәүләт ярдәменең өстәмә чаралары турында» Россия Федерациясе Президентының 1992 елның 2 октябрендәге 1157 номерлы Указы.

**Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документлар һәм белешмәләрнең тулы исемлеге**

2.8. Муниципаль хезмәттән файдалану өчен гариза бирүче түбәндәге документларны тапшыра:

2.8.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында әлеге Административ регламентка 7 нче кушымта нигезендә электрон рәвештә һәм 8 нче кушымта нигезендә кәгазьдә гариза һәм әлеге Административ регламентның 2.8.2-2.8.8 пунктлары нигезендә документлар, шул исәптән гаризага кушып бирелә торган электрон документлар рәвешендә дә. Гариза ЕПГУ һәм/яисә РПГУ аша җибәрелгән очракта, гаризаны, нинди дә булса башка формада гариза бирмичә, ЕПГУ һәм/яисә РПГУда интерактив форманы тутыру юлы белән формалаштыралар.

2.8.2. Гариза бирүченең шәхесен раслый торган документ.

Гаризаны ЕПГУ һәм/яисә РПГУ аша җибәргәндә, гариза бирүченең шәхесен раслаучы документ турында кулланучы тарафыннан ЕСИА төзегәндә һәм хисап язмасын раслаганда күрсәтелгән белешмәләр тапшырыла.

2.8.3. Гариза бирүченең Россия Федерациясендә булу хокукын раслый торган документ, баланың шәхесен раслый торган һәм бала хокукларын тапшыруның законлылыгын раслый торган документ(-лар) (гариза бирүче –чит ил гражданы йә гражданлыгы булмаган зат өчен).

2.8.4. Опека билгеләүне раслый торган документ (кирәк булганда).

2.8.5. Психологик-медик-педагогик комиссия документы (кирәк булганда).

2.8.6. Сәламәтләндерү юнәлешендәге төркемдә белем алу ихтыяҗын раслый торган документ (кирәк булганда).

2.8.7. Гражданнарның аерым категорияләренә һәм аларның гаиләләренә ярдәм итүнең махсус чараларына (гарантияләргә) хокукы булу турындагы белешмәләр (кирәк булганда).

2.8.8. Баланың тору урыны, фактта яшәү урыны турында белешмәләрне үз эченә алган документ (беркетелгән территориядә яшәү урыны буенча яки тору урыны буенча баланы теркәү турында таныклык булмаганда).

Кәгазьдә бирелгән гаризада шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен җибәрүнең түбәндәге ысулларының берсе күрсәтелә:

телефон, электрон почта аша хәбәрнамә формасында;

Вәкаләтле органда кәгазьдә электрон документның бастырылган нөсхәсе рәвешендә, күпфункцияле үзәктә һәм/яки гаризада күрсәтелгән почта адресы буенча җибәреп.

2.9. Гариза бирүче, юллама өчен кәгазьдә тапшырылган гариза буенча мәгълүмат алу турында ЕПГУда гариза тутырып, нәтиҗәне өстәмә рәвештә ЕПГУда да ала ала.

**Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы башка органнар һәм оешмалар карамагында булган, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документлар һәм белешмәләрнең тулы исемлеге**

2.10. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы башка органнар һәм оешмалар карамагында булган, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документлар һәм белешмәләрнең тулы исемлеге, мөрәҗәгать иткән очракта:

- Россия Федерациясе территориясендә бирелгән баланың туу турында таныклыгы;
- Беркетелгән территориядә яшәү урыны яки тору урыны буенча баланы теркәү турында таныклык, яисә яисә баланың тору урыны, факттагы яшәү урыны турында мәгълүмат булган документлар.

2.11. Муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:

2.11.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүгә бәйле барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актлар белән тапшыру яисә гамәлгә ашыру каралмаган документлар һәм мәгълүмат бирү яисә гамәлләрне башкару;

2.11.2. Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, Кукмара муниципаль районының муниципаль хокукый актлары нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтүче органнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы дәүләт органнарына һәм (яисә) җирле үзидарә органнарына буйсынган оешмалар карамагында булган документлар һәм мәгълүматлар тапшырулар, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 6 өлешендә (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) күрсәтелгән документлардан тыш.

2.11.3. Түбәндәге очраклардан тыш, муниципаль хезмәт күрсәткәндә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән беренчел баш тартканда, аларның булмавы һәм (яки) дөрес түгеллеге күрсәтелмәгән документлар яисә мәгълүмат тапшыру:

беренче тапкыр муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза бирелгәннән соң, муниципаль хезмәт күрсәтүгә кагылышлы норматив хокукый актлар таләпләре үзгәрү;

муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гаризада һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканнан соң гариза бирүче тарафыннан тапшырылган документларда яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдә элек тапшырылган документлар комплектына кертелмәгән хаталар булу;

муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән йә муниципаль хезмәт күрсәтүдән беренче тапкыр баш тартканнан соң, документларның гамәлдә булу срогы узу яисә мәгълүматны үзгәртү;

муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдән беренче тапкыр баш тартканда Вәкаләтле органның вазыйфаи затының, КФҮ хезмәткәренең, эшчесенең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешма хезмәткәренең хаталы яисә хокукка каршы гамәленең (гамәл кылмавының) документаль расланган фактын (билгеләрен) ачыклау, бу турыда муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканда Вәкаләтле орган җитәкчесе, күпфункцияле үзәк җитәкчесе яисә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешма җитәкчесе имзасы белән язмача гариза бирүчегә хәбәр ителә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенәләр;

**Гаризаны кәгазьдә биргәндә, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге**

2.12. Кәгазьдә гариза биргәндә, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны карап тикшерүгә кабул итүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

- әлеге Административ регламентның 2.8 пункты нигезендә тулы булмаган мәгълүмат тапшыру (гариза бирүчедән документлар җыелмасы), гариза бирүче тарафыннан җитешсезлекләрне төзәтү вакытын исәпкә алып;
- гариза бирүче тарафыннан тапшырылган документлар текстында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган бозулар, чистартулар һәм төзәтүләр бар;

**Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору яки муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге**

2.13. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.

2.14. Арадаш нәтиҗә – исәпкә кую өлешендә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту нигезләре:

- гариза бирүче хезмәт күрсәтүгә хокукка ия булган затлар категориясенә туры килми;

- әлеге Административ регламентның 2.8 пункты нигезендә дөрес булмаган мәгълүмат бирү;

- тапшырылган документлар яки белешмәләр хезмәт сорап мөрәҗәгать иткән вакытка үз көчләрен югалткан (гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ, муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап күрсәтелгән зат мөрәҗәгать иткән очракта);

- гариза формасында, шул исәптән интерактив рәвештә ЕПГУда гариза формасында мәҗбүри кырларны дөрес тутырмау (ышанычлы булмаган, тулы булмаган яки дөрес булмаган тутыру) *(гаризаны электрон рәвештә биргәндә)*;

- тулы булмаган мәгълүмат, шул исәптән тулы булмаган документлар җыелмасы тапшыру *(гаризаны электрон рәвештә биргәндә)*;

- хезмәт күрсәтү турында гариза хезмәт күрсәтү алар вәкаләтләренә керми торган дәүләт хакимияте органына, җирле үзидарә органына яки оешмага тапшырылган *(при подаче заявления на бумажном носителе)*.

Төп нәтиҗә – юллама өлешендә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр каралмаган.

**Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнаша торган орган һәм оешмалар тарафыннан бирелә торган документ (документлар) турында мәгълүматлар**

2.15. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр юк.

**Муниципаль хезмәт күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре**

2.16. Муниципаль хезмәт күрсәтү бушлай башкарыла.

**Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәк һәм мәҗбүри булган хезмәт күрсәтүләр өчен түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре, шул исәптән мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүмат**

2.17. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр юк.

**Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза биргәндә һәм кәгазьдә гариза биргәндә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты**

2.18. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза биргәндә һәм муниципаль хезмәт күрсәтүнең арадаш нәтиҗәсен алганда Вәкаләтле органда яки күпфункцияле үзәктә чиратны көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмый.

## Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны, шул исәптән электрон формада теркәү вакыты һәм тәртибе

2.19. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризалар гариза һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны алганнан соң 1 эш көне эчендә Вәкаләтле органда теркәлергә тиеш.

Гаризаны кәгазьдә биргәндә, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез булган очракта, җитешсезлекләрне төзәтү вакытын исәпкә алып, Вәкаләтле орган кимчелекләрне төзәтү өчен билгеләнгән вакытның соңгы көненнән соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә әлеге Административ регламентка 9 нчы кушымтада китерелгән форма буенча муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар җибәрә.иза бирүчегә карар җибәрә.

## Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр

2.20. Кәгазьдә гаризалар һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар кабул ителә, шулай ук кәгазьдә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре бирелә торган административ биналарның урнашу урыны җәмәгать транспорты тукталышларыннан җәяү бару мөмкинлеге күзлегеннән чыгып, гражданнар өчен уңайлы булырга тиеш.

Гариза бирүчеләрнең, шул исәптән инвалид коляскаларында йөрүчеләрнең тоткарлыксыз үтеп керүен тәэмин итү максатларында, муниципаль хезмәт күрсәтелә торган бинага керү урыннары пандуслар, култыксалар, тактиль (контраст) кисәтү элементлары, инвалидларны социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә инвалидларның тоткарлыксыз үтеп керүен һәм хәрәкәт итүен тәэмин итә торган башка махсус җайланмалар белән җиһазлана.

Вәкаләтле орган бинасына үзәк керү юлы түбәндәге мәгълүмат булган мәгълүмати такта (билге) белән җиһазландырылырга тиеш:

атамасы;

урнашу урыны һәм юридик адресы;

эш режимы;

кабул итү графигы;

белешмәләр өчен телефон номерлары.

Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналар санитар-эпидемиологик кагыйдәләргә һәм нормативларга туры килергә тиеш.

Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналар түбәндәгеләр белән җиһазландырыла:

янгынга каршы системасы һәм янгын сүндерү чаралары; гадәттән тыш хәл турында хәбәр итү системасы; килүчеләр өчен бәдрәф бүлмәләре.

Гариза бирүчеләр өчен көтү залы урындыклар, эскәмияләр белән җиһазландырылачак, аларның саны фактик йөкләмәдән һәм аларны бүлмәгә урнаштыру мөмкинлекләреннән чыгып билгеләнә, шулай ук мәгълүмати стендлар урнаштырыла.

Мәгълүмат стендында урнаштырылган материалларның текстлары укырга уңайлы шрифт белән, төзәтүләрсез, иң мөһим урыннары калын шрифт белән бастырыла.

Гаризаларны тутыру урыннары урындыклар, өстәлләр (стойка), гариза бланклары, язу кирәк-яраклары белән җиһазландырыла.

Гариза бирүчеләрне кабул итү урыннары мәгълүмати табличкалар (элмә такталар) белән җиһазландырылачак, анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

кабинет номеры һәм бүлек исеме;

документларны кабул итү өчен җаваплы затның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (соңгысы – булган очракта), вазыйфасы;

гариза бирүчеләрне кабул итү графигы.

Документлар кабул итү өчен җаваплы һәр затның эш урыны кирәкле мәгълүмат базасына керү мөмкинлеге булган шәхси компьютер белән, бастыру җайланмасы (принтерга) һәм күчергеч җайланма белән җиһазландырылырга тиеш.

Документлар кабул итү өчен җаваплы затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (соңгысы – булган очракта) һәм вазыйфасы күрсәтелгән өстәл язмасы булырга тиеш.

Инвалидларга муниципаль хезмәт күрсәткәндә түбәндәгеләр тәэмин ителә:

муниципаль хезмәт күрсәтелә торган объектка (бинага, бүлмәгә) тоткарлыксыз керү мөмкинлеге;

муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналар һәм бүлмәләр урнашкан территория буенча мөстәкыйль йөрү, шулай ук мондый объектларга мөстәкыйль керү һәм чыгу мөмкинлеге, транспорт чарасына утырту һәм аннан төшерү, шул исәптән коляскалы урындыкны куллану мөмкинлеге;

күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функциясе бозылган инвалидларны озатып бару;

инвалидларның хезмәт күрсәтә торган биналарга һәм бүлмәләргә һәм муниципаль хезмәтләргә тоткарлыксыз керүен тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат йөртү чыганакларын, аларның тормыш эшчәнлеген чикләүне исәпкә алып, тиешенчә урнаштыру;

махсус өйрәтелүен раслаучы документы булганда, муниципаль хезмәт күрсәтелә торган объектларга (биналарга, бүлмәләргә) озатып йөрүче этне кертү;

инвалидларга муниципаль хезмәт күрсәтүләрдән башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә файдалануга комачаулый торган каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү

.

**Мунципаль хезмәтенең үтемлелеге һәм сыйфаты күрсәткечләре**

2.21. Муниципаль хезмәттән һәркем файдалана алу мөмкинлегенең төп күрсәткечләренә түбәндәгеләр керә:

гомуми файдаланудагы мәгълүмати телекоммуникация челтәрләрендә (шул исәптән «Интернет» челтәрендә), массакүләм мәгълүмат чараларында муниципаль хезмәт күрсәтүнең тәртибе, вакыты һәм барышы турында тулы һәм аңлаешлы мәгълүмат булу;

муниципаль хезмәт күрсәтүнең барышы турында, шул исәптән ЕПГУ һәм/яки РПГУ ярдәмендә мәгълүмат алу мөмкинлеге;

гариза бирүченең муниципаль белем бирү оешмасында урын бирү эзлеклелеге турында, шул исәптән ЕПГУ һәм/яки РПГУ дан файдаланып, мәгълүмат алу мөмкинлеге.

2.22. Муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфатының төп күрсәткечләренә түбәндәгеләр керә:

әлеге Административ регламентта билгеләнгән хезмәт күрсәтү стандарты нигезендә муниципаль хезмәтнең үз вакытында күрсәтелүе;

минималь мөмкин булган муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи затлар белән гражданның үзара хезмәттәшлеге саны;

хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмавына) нигезле шикаятьләр булмау һәм аларның гариза бирүчеләргә карата дөрес булмаган (игътибарсыз) мөнәсәбәте;

муниципаль хезмәт күрсәтү процессында Вәкаләтле орган тарафыннан билгеләнгән срокларны бозулар булмау;

аларны карау йомгаклары буенча гариза бирүчеләрнең таләпләрен канәгатьләндерү (өлешчә канәгатьләндерү) турында карарлар чыгарылган муниципаль хезмәт күрсәткәндә кабул ителгән (кылынган) карарларга карата Вәкаләтле органның, аның вазыйфаи затларының карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) дәгъва белдерү турында гаризалар булмау.

**Башка таләпләр, шул исәптән күпфункцияле үзәкләрдә дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен, экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен исәпкә алучы һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләре**

2.23. Экстерриториаль принцип буенча муниципаль хезмәт күрсәтү ЕПГУ һәм/яисә РПГУ аша гаризалар бирү мөмкинлеген тәэмин итү һәм күпфункцияле үзәктә муниципаль хезмәт нәтиҗәләрен алу өлешендә гамәлгә ашырыла.

2.24. Гариза бирүчеләргә муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле гаризаны, документлар һәм кирәкле белешмәләрне электрон рәвештә ЕПГУ һәм/ яки РПГУ аша җибәрү мөмкинлеге тәэмин ителә.

Муниципаль хезмәттән файдалану өчен гариза бирүче ЕПГУ һәм/яисә РПГУда шәхси зат (физик зат) ролендә ЕСИАда расланган хисап язмасы белән авторизация үтәргә, муниципаль хезмәтнең атамасын күрсәтергә һәм тәкъдим ителгән интерактив гариза формасын тутырырга тиеш.

Гариза гариза бирүченең гади электрон имзасы белән имзалана һәм Ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша Вәкаләтле органга җибәрелә. Муниципаль хезмәтнең электрон формасы 2.8.3-2.8.8 пунктларында каралган Вәкаләтле органның (оешманың) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән расланган документларны электрон рәвештә беркетү мөмкинлеген күздә тота,

Муниципаль хезмәт күрсәтүнең әлеге Административ регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән нәтиҗәләре гариза бирүчегә ЕПГУ һәм/яисә РПГУда шәхси кабинетына гариза буенча хәбәрнамәләр рәвешендә җибәрелә.

Гаризаны ЕПГУ һәм/яисә РПГУ аша җибәргән очракта, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе шулай ук гариза бирүчегә Вәкаләтле органда, күпфункцияле үзәктә кәгазьдә бирелергә мөмкин.

2.25. 2.8.3-2.8.8 пунктларында каралган электрон документларны ЕПГУ аша тапшырганда, мондый документлар pdf, jpg, jpeg с sig форматларында бирелә.

Электрон документлар түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

- документны һәм документтагы битләр санын тиңләштерү мөмкинлеге;
- өлешләр, бүлекләр, раздел (подраздел) буенча структураланган мәгълүматларны һәм исемлек буенча һәм (яки) тексттагы рәсемнәргә һәм таблицаларга күчүне тәэмин итә торган билгеләрне (закладка) үз эченә алган документлар өчен.

## III. Административ процедураларны (гамәлләрне) башкаруның составы, эзлеклелеге һәм вакыты, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән электрон формада административ процедураларны үтәү үзенчәлекләре

### Формасына карамастан, административ процедураларның тулы исемлеге

3.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гаризаларны һәм башка документларны кабул итү һәм теркәү;

документларны һәм белешмәләрне карау;

карар кабул итү;

арадаш нәтиҗәне бирү;

муниципаль хезмәтнең төп нәтиҗәләрен юридик әһәмиятле язмалар реестрына кертү.

Административ процедураларның тасвирламасы әлеге Административ регламентка 11 нче кушымтада күрсәтелгән.

### ЕПГУ һәм/яисә РПГУ аша электрон формада муниципаль хезмәт күрсәткәндә административ процедуралар (гамәлләр) исемлеге

3.2. Муниципаль хезмәтләрне электрон формада күрсәткәндә, гариза бирүчегә өстәмә рәвештә түбәндәгеләр тәэмин ителә:

муниципаль хезмәтләрне электрон формада күрсәтү тәртибе һәм вакыты турында мәгълүмат алу;

гаризаны электрон формада формалаштыру;

электрон формадагы гаризаны карау барышы турында белешмәләр алу;

гариза бирүченең соратуы буенча башка формаларда бирелгән гаризаны карау барышы турында ЕПГУда мәгълүмат алу мөмкинлеге;

муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфатын бәяләү;

Вәкаләтле органның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата яисә Вәкаләтле органның муниципаль хезмәт күрсәтүче вазыйфаи затларының яисә муниципаль хезмәткәрнең гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү.

**Хезмәт күрсәтүнең формасына карамастан, административ процедураларны (гамәлләрне) башкару тәртибе**

3.3. Гариза формалаштыру.

Гариза электрон рәвештә ЕПГУ һәм/яисә РПГУда формалаштырылырга мөмкин, яисә кәгазьдә бирелергә мөмкин.

Гаризаны электрон формада формалаштыру кәгазьдә өстәмә гариза бирүне таләп итми.

Гаризаны электрон формада формалаштырганда, гариза бирүче гаризаның электрон формасындагы һәр кырны тутырганнан соң, форматлы-логик тикшерү үткәрелә. Гаризаның электрон формасындагы дөрес тутырылмаган кырны ачыклаганда, гариза бирүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны турыдан-туры гаризаның электрон формасында бетерү тәртибе турында хәбәр ителә.

ЕПГУ һәм/яисә РПГУ аша гариза формалаштырганда гариза бирүчегә түбәндәгеләр тәэмин ителә:

а) кулланучының теләге буенча электрон гариза формасына элек кертелгән күрсәткечләрне теләсә кайсы мизгелдә саклап калу, шул исәптән керткәндә хаталар барлыкка килгәндә һәм гаризаның электрон формасына күрсәткечләрне кабат кертү өчен кире кайтарылганда;

б) гариза бирүченең ЕСИАдагы профилендә урнаштырылган мәгълүматлар нигезендә электрон гаризадагы кырларны автомат рәвештә тутыру мөмкинлеге;

в) элек кертелгән мәгълүматны югалтмыйча, гаризаның электрон формасын тутыруның теләсә кайсы этапларына әйләнеп кайту мөмкинлеге;

г) гариза бирүченең ЕПГУ һәм/яисә РПГУга элек ЕПГУ һәм/яисә РПГУда бирелгән гаризаларга керү мөмкинлеге.

ЕПГУ һәм/яисә РПГУда формалаштырылган гариза Ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә мәктәпкәчә белем бирүнең һәркем файдалана алырлык төбәк мәгълүмат системасына җибәрелә.

3.4. РГИС ДДОга кергәннән соң, электрон гариза Вәкаләтле органның гаризаны кабул итү һәм теркәү өчен җаваплы вазыйфаи заты өчен (алга таба – җаваплы вазыйфаи заты) ачык була.

3.5. Вәкаләтле органның җаваплы вазыйфаи заты ЕПГУ һәм/яисә РПГУдан килгән электрон гаризаларның керүен көненә кимендә 2 тапкыр тикшерә.

3.6. Вәкаләтле органның җаваплы вазыйфаи заты түбәндәгеләрне тәэмин итә:

а) гариза бирелгәннән соң 1 эш көненнән дә соңга калмыйча, ә ул эш көне булмаган яисә бәйрәм көнендә кергән очракта – аннан соң килүче эш көнендә дәүләт (муниципаль) хезмәт күрсәтү турында гаризаны эшләү өчен кабул итү. Шул ук вакытта гариза бирүчегә ЕПГУ һәм/яисә РПГУга «Гаризаны карау башланды» дигән хәбәрнамә җибәрелә.

Гаризадагы мәгълүматларны раслау кирәк булган очракта, гариза бирүчегә бу турыда ЕПГУ һәм/яисә РПГУга «Гаризадагы мәгълүматларны раслау өчен, Сезгә ________________________ *(документларны тапшыру урыны күрсәтелә)* ________________________ вакытта *(документларны тапшыру вакыты күрсәтелә)* түбәндәге документларны тапшырырга кирәк» ________________________ *(гариза бирүче тапшырырга тиешле раслаучы документлар исемлеге күрсәтелә»* дип хәбәр ителә. Әлеге җитешсезлекләр гариза бирүче тарафыннан хәбәр итү көненнән алып, шул исәптән тиешле хәбәрнамә кергәннән соң *3 көн* эчендә төзәтелергә мөмкин, аны үтәмәгәндә әлеге Административ регламентның 2.12. һәм 2.14 пунктлары нигезендә баш тартылачак.

б) гаризаны карау. Гаризаны карауның арадаш нәтиҗәсе буларак, гариза бирүчегә, шул исәптән ЕПГУ һәм/яки РПГУда хәбәрнамә формасында «Сезнең гариза каралды. Гаризаның индивидуаль номеры ________________. Сайланган белем бирү оешмасына _ _ _ _ _ _ _ *(гаризада күрсәтелгән кирәкле кабул итү датасы күрсәтелә)* соң юллама көтегез.» *(хезмәтнең уңай арадаш нәтиҗәсе)* яисә «Сезгә агымдагы гариза буенча хезмәт күрсәтүдән ________________ сәбәбе буенча *(гариза буенча тискәре карар кабул ителүнең сәбәбе күрсәтелә)* баш тартылды. Сезгә ____________ *(гариза буенча уңай нәтиҗә алу өчен, гариза бирүче башкарырга тиешле гамәлләр тәртибе күрсәтелә)*кирәк.» *(хезмәтнең тискәре арадаш нәтиҗәсе)*

Белем бирү оешмаларында кирәкле кабул итү вакыты җиткәч, гаризада гариза бирүче тарафыннан күрсәтелгән буш урыннар булмаганда *(РГИС ДДО мәгълүматлары буенча)* гариза бирүчегә,шул исәптән ЕПГУ һәм/яки РПГУда хәбәрнамә формасында хәбәр ителә: «Хәзерге вакытта гаризада күрсәтелгән белем бирү оешмаларында гаризада соралган шартларга туры килгән буш урыннар юк. Сезгә _________ *(мөмкин булган оракта урыннар бирелергә мөмкин булган белем бирү оешмалары исемлеге күрсәтелә)* урын тәкъдим ителергә мөмкин. Әлеге белем бирү оешмасында урын алуга риза булган очракта, Сезгә юллама өчен гаризада

кабул итү өчен сайланган мәктәпкәчә белем бирү оешмалары исемлеген үзгәртергә кирәк», дип хәбәр ителә.

Кабул итүнең кирәкле датасы җиткәч һәм гариза бирүче гаризада күрсәткән белем бирү оешмаларында буш урыннар булганда *(РГИС мәгълүматлары буенча)*, бала өчен урын билгеләү турында мәгълүмат булган юллама турындагы документ расланганнан һәм әлеге документның реквизитларын РГИСка керткәннән соң, гариза бирүчегә ЕПГУ һәм/яисә РПГУга «Сезгә _____________ *(белем бирү оешмасының иseme, төркем турында мәгълүмат күрсәтелә)* _________________________ нигезендә *(баланы мәктәпкәчә белем бирү оешмасына җибәрү турында документ реквизитлары күрсәтелә)* урын бирелде» дигән хәбәрнамә җибәрелә. Сезгә ____________ *(статусны күрсәткәннән соң, гамәлне үтәү вакытын күрсәтеп, гариза бирүченең гамәлләре тәртибе тасвирлана) (хезмәт күрсәтүнең уңай төп нәтиҗәсе)* кирәк».

3.7. ЕПГУга гариза биргәндә, гариза бирүчегә хәбәрнамә рәвешендә ЕПГУда муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алу яисә, РПГУга гариза биргәндә, башка формада бирелгән гаризалар турында мәгълүмат алуны сораганда, РПГУда хәбәрнамә рәвешендә, шәхесе яшерелгән хәлдә Вәкаләтле орган сайтында яки стендында алу мөмкинлеге бирелә. Кирәк булган очракта, гариза бирүче шулай ук Вәкаләтле органга шәхсән мөрәҗәгать иткәндә юллама турындагы документтан өземтә рәвешендә дә нәтиҗәне ала ала.

3.7.1. Хезмәт нәтиҗәләре:

3.7.1.1. Оешмага юллама.

Чираттагы уку елына белем бирү учреждениеләрен комплектлау төркемнәрдә расланган буш урыннар саны нигезендә һәм балаларның яшь категориясе буенча 1 июньнән 31 августка кадәр башкарыла.

Буш урыннар булганда, белем бирү оешмаларын туплау ел дәвамында, балаларның яшь категориясе нигезендә гамәлгә ашырыла.

Административ процедураны башкара башлау өчен нигез булып АИС ЭДСта гаризаның «Теркәлгән» статусында булуы, теркәлгән чират нигезендә баланы җибәрү өчен Оешмада җитәрлек күләмдә буш урыннар булу тора. Гариза бирүче чираты якынлашканда һәм теләгән Оешмада тиешле яшь төркемендә урын булган очракта, Вәкаләтле хезмәткәр тарафыннан баланы АИС ЭДС аша оешмага юллау гамәлгә ашырыла. Гаризага «Мәктәпкәчә белем бирү оешмасына җибәрелгән» статусы бирелә. Процедураларның нәтиҗәсе: Системада гаризага «Мәктәпкәчә белем бирү оешмасына җибәрелгән» статусын бирү.

Гариза бирүче «Мәктәпкәчә белем бирү оешмасына җибәрелгән» статусын алганнан соң, 30 календарь көнгә кадәр баланы кабул итүне раслау өчен, Оешмага мөрәҗәгать итә. Оешма җитәкчесе Гариза бирүче баланы кабул итү турында гариза белән мөрәҗәгать иткән көннән алып 5 эш көне эчендә АИС ЭДСта гаризага «Шартнамә төзү» статусын бирә. Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар Гариза бирүче мөрәҗәгать иткән мизгелдән 5 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла. Процедураларның нәтиҗәсе: АИС ЭДСта гаризага «Шартнамә төзү» статусын бирү.

Әгәр Гариза бирүчене бала җибәрелгән Оешма канәгатьләндермәсә, Гариза бирүче тарафыннан әлеге Оешмага юлламадан баш тарту рәсмиләштерелә.

Тәкъдим ителгән оешмага юлламадан баш тарту Вәкаләтле органга шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, Вәкаләтле орган тарафыннан билгеләнгән форма буенча язма рәвештә рәсмиләштерелә.

АИС ЭДСта гаризага «Теркәлгән» статусы бирелә. Шул ук вакытта исәпкә кую датасы үзгәрми. Теләгән кабул итү вакыты Гариза бирүченең юлламадан баш тарту турында мөрәҗәгать иткән көненнән дә иртәрәк булмаган датага алыштырыла. Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар Гариза бирүче мөрәҗәгать иткән мизгелдән 1 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: АИС ЭДСта гаризага «Теркәлгән» статусын бирү, тәкъдим ителгән Оешмага юлламадан баш тарту.

Гариза бирүче гаризага «Мәктәпкәчә белем бирү оешмасына җибәрелгән» статусын биргәннән соң Регламентта билгеләнгән вакытта Оешмага килмәгән очракта, АИС ЭДСта автомат рәвештә гаризага «Килмәде» статусы бирелә. Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар 1 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла. Процедураларның нәтиҗәсе: АИС ЭДСта гаризага «Килмәде» статусын бирү.

Әгәр гариза бирүче үзенең хезмәттән файдалану теләген раслый икән, гаризага «Теркәлгән» статусы бирелә. Шул ук вакытта исәпкә кую датасы үзгәрми. Әгәр гариза бирүче муниципаль хезмәттән файдаланудан баш тартса, гаризага «Хезмәт күрсәтүдән баш тартылды» статусы бирелә. Раслау яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдән файдаланудан баш тарту Вәкаләтле органга шәхсән мөрәҗәгать иткәндә язмача рәсмиләштерелә. Расланганда, теләгән кабул итү вакыты Гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтүгә ихтыяҗын раслап мөрәҗәгать иткән көненнән дә иртәрәк булмаган датага алыштырыла. Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар Гариза бирүче мөрәҗәгать иткән мизгелдән 1 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла. Процедураларның нәтиҗәсе: АИС ЭДСта гаризага «Теркәлгән» яисә «Хезмәт күрсәтүдән баш тартылган» статусын бирү.

3.7.1.2. Оешмага кабул итү.

«Шартнамә төзү» статусы бирелгәннән соң бер ай эчендә Гариза бирүче Оешмага шартнамә төзү өчен мөрәҗәгать итә. Ата-аналар (законлы вәкилләр) белән шартнамә төзегәннән соң, Оешма җитәкчесе АИС ЭДСта гаризага «Мәктәпкәчә белем бирү оешмасына кабул ителде» статусын бирә. Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар ата-аналар (законлы вәкилләр) белән шартнамә төзегәннән соң 1 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла. Процедураларның нәтиҗәсе: АИС ЭДСта гаризага «Мәктәпкәчә белем бирү оешмасына кабул ителгән» статусын бирү.

Гариза бирүче Регламентта билгеләнгән вакытта шартнамә төзергә килмәгән очракта, Оешма җитәкчесе гаризага «Килмәде» статусын бирә. Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар «Шартнамә төзү» статусы бирелгән көннән бер айлык срок исәпләнгәннән соң 1 эш көне эчендә башкарыла.Процедураларның нәтиҗәсе: АИС ЭДСта гаризага «Килмәде» статусын бирү.

Әгәр гариза бирүче үзенең хезмәттән файдалану теләген раслый икән, гаризага «Теркәлгән» статусы бирелә. Шул ук вакытта исәпкә кую датасы үзгәрми.

Расланганда, теләгән кабул итү вакыты Гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтүгә ихтыяҗын раслап мөрәҗәгать иткән көненнән дә иртәрәк булмаган датага алыштырыла. Әгәр гариза бирүче муниципаль хезмәттән файдаланудан баш тартса, гаризага «Хезмәт күрсәтүдән баш тартылды» статусы бирелә. Раслау яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдән файдаланудан баш тарту Мәгариф идарәсе муниципаль органына Вәкаләтле орган тарафыннан билгеләнгән форма буенча шәхсән мөрәҗәгать иткәндә язмача рәсмиләштерелә. Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар Гариза бирүче мөрәҗәгать иткән мизгелдән 1 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла. Процедураларның нәтиҗәсе: АИС ЭДСта гаризага «Теркәлгән» яисә «Хезмәт күрсәтүдән баш тартылган» статусын бирү.

Баланы билгеле бер вакытка (вакытлыча, медицина бәяләмәсе яки психологик-медик-педагогик комиссия бәяләмәсе нигезендә) компенсацияләүче яки сәламәтләндерү юнәлешендәге төркемгә җибәргән очракта, Вәкаләтле хезмәткәр АИС ЭДСтагы юлламада «Вакытлыча кабул итү» дигән билге куя.Баланың гаризасы исәпкә куюның беренчел датасы белән чиратта саклана. Әгәр бала компенсацияләүче яки сәламәтләндерү юнәлешендәге төркемгә җибәрелгән вакытта башка Оешмага йөргән булса, Оешма җитәкчесе, махсуслаштырылган төркемдә булуның тәмамлану вакыты датасын күрсәтеп, баланы вакытлыча чыгарып җибәрә.

3.8. Гариза бирү ысулының нинди булуына карамастан, гариза бирүчегә аның соратуы буенча гаризаны карау барышы һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында мәгълүматны ЕПГУ һәм/яки РПГУдан алу мөмкинлеге бирелә.

ЕПГУда муниципаль хезмәттән файдалану өчен, гариза бирүче ЕСИАда шәхси зат (физик зат) ролендә расланган хисап язмасы белән авторизация үтәргә, «Шәхсән кабул итү вакытында бирелгән гаризалар буенча мәгълүматка язылырга» хезмәт күрсәтү вариантын сайларга, аннары «Хезмәтне алу» төймәсе буенча интерактив гариза формасын ачарга, аны тутырырга һәм гариза бирергә тиеш.

3.9. Муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфатын бәяләү.

Муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең сыйфатын бәяләү «Дәүләт хезмәтләрен күрсәтү сыйфатын исәпкә алып, башкарма хакимиятнең федераль органнары (аларның структур бүлекчәләре) территориаль органнары һәм бюджеттан тыш дәүләт фондларының территориаль органнары (аларның төбәк бүлекчәләре), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру сыйфатын исәпкә алып, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре җитәкчеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген гражданнар тарафыннан бәяләү, шулай ук тиешле җитәкчеләрнең үз вазыйфа йөкләмәләрен вакытыннан алда туктату турында карар кабул итү өчен нигез буларак күрсәтелгән бәяләү нәтиҗәләрен куллану турында» 2012 елның 12 декабрендәге 1284 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт хезмәтләрен күрсәтү сыйфатын исәпкә алып, башкарма хакимиятнең федераль органнары (аларның структур бүлекчәләре) территориаль органнары җитәкчеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген гражданнар тарафыннан бәяләү, шулай ук тиешле җитәкчеләрнең үз вазыйфа йөкләмәләрен вакытыннан

алда туктату турында карар кабул итү өчен нигез буларак күрсәтелгән бәяләү нәтиҗәләрен куллану кагыйдәләре consultantplus://offline/ref=7477D36D247F526C7BD4B7DDD08F15A6014F84D62298DDA4DCA8A2DB7828FD21BF4B5E0D31D769E7uBz4M нигезендә башкарыла.

3.10. Гариза бирүчегә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 11.2 статьясы нигезендә һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә кылынган карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмау) судка кадәр, (судтан тыш) шикаять бирү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы турында" 2012 елның 20 ноябрендәге 1198 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән билгеләнгән тәртиптә Вәкаләтле органның, Вәкаләтле органның вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәрнең карарларына, гамәлләренә яки гамәл кылмавына шикаять җибәрү мөмкинлеге тәэмин ителә.

## Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә кәгазь формада бирелгән документларда җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтү тәртибе

3.10. Басмада хаталар һәм хаталар ачыкланган очракта, гариза бирүче Вәкаләтле органга гариза белән Административ регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән документларны теркәп мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

3.11. Басма хаталарны һәм хаталарны төзәтү турында гариза кабул итүдән баш тарту нигезләре Административ регламентның 2.12 пунктында күрсәтелгән.

3.12. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә кәгазь формада бирелгән документларда җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтү түбәндәге тәртиптә башкарыла:

3.12.1. Гариза бирүче, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы басмадагы хаталар һәм хаталар ачыкланган очракта, шәхсән Вәкаләтле органга басамадагы хаталарны һәм хаталарны төзәтү зарурлыгы турында, аларның тасвирламасын күрсәтеп, гариза белән мөрәҗәгать итә.

3.12.2. Вәкаләтле орган әлеге бүлекчәнең 3.12.1 пунктчасында күрсәтелгән гаризаны алгач, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документларга тиешле үзгәрешләр кертү кирәклеген карый.

3.12.3. Вәкаләтле орган муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документлардагы басмадагы хаталарны һәм хаталарны бетерүне тәэмин итә.

3.12.4. Басмадагы хаталарны һәм хаталарны бетерү срогы әлеге бүлекчәнең 3.12.1 пунктчасында күрсәтелгән гаризаны теркәү датасыннан 3 (өч) эш көненнән дә артмаска тиеш.

# IV. Административ регламентның үтәлешен тикшереп тору формалары

## Җаваплы вазыйфаи затлар тарафыннан регламент нигезләмәләренең һәм муниципаль хезмәт күрсәтүгә таләпләрне билгели торган башка норматив хокукый актларның үтәлешен һәм башкарылуын агымдагы контрольдә

**тотуны гамәлгә ашыру тәртибе, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул итү**

4.1. Әлеге Административ регламентның, муниципаль хезмәт күрсәтүгә таләпләрне билгели торган башка норматив хокукый актларның үтәлешенә һәм башкарылуына агымдагы контроль даими нигездә Вәкаләтле органның муниципаль хезмәт күрсәтүне тикшереп торырга вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Агымдагы контроль өчен хезмәт корреспонденциясе мәгълүматлары, Вәкаләтле орган белгечләренең һәм вазыйфаи затларының телдән һәм язма мәгълүматлары кулланыла.

Агымдагы контроль тикшерүләр үткәрү юлы белән башкарыла: муниципаль хезмәтләр күрсәтү (баш тарту турында) карарлар, гражданнарның хокукларын бозуларны ачыклау һәм бетерү;

вазыйфаи затларның карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр булган гражданнар мөрәҗәгатьләренә җавапларны карау, карарлар кабул итү һәм җаваплар әзерләү.

**Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгы һәм сыйфаты буенча планлы һәм планнан тыш тикшерүләрне гамәлгә ашыру тәртибе һәм чоры, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшереп тору тәртибе һәм формалары**

4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту планлы һәм планнан тыш тикшерүләр үткәрүне үз эченә ала.

4.3. Планлы тикшерүләр Вәкаләтле органның Вәкаләтле орган җитәкчесе тарафыннан раслана торган еллык эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын планлы тикшергәндә түбәндәгеләр контрольгә алынырга тиеш:

муниципаль хезмәт күрсәтү срокларын үтәү;

әлеге Административ регламент нигезләмәләрен үтәү;

муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында кабул ителгән карарның дөреслеге һәм нигезлелеге.

Планнан тыш тикшерүләр үткәрүнең нигезе булып түбәндәгеләр тора:

дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан Россия Федерациясе норматив хокукый актларын, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы норматив хокукый актларын күздә тотылган бозу яисә ачыкланган бозулар турында мәгълүмат алу;

гражданнарның һәм юридик затларның закон бозуларга, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфатына карата мөрәҗәгатьләре

.

**Вазыйфаи затларның муниципаль хезмәт күрсәтү барышында алар кабул итә торган (гамәлгә ашыра торган) карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) өчен җаваплылыгы**

4.4. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча, әлеге Административ регламент нигезләмәләрен, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы норматив хокукый актларын бозу очраклары ачыкланганда, гаепле затларны Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тарту гамәлгә ашырыла.

Муниципаль хезмәт күрсәтүне (бирүдән баш тарту турында) кКарар кабул итүнең дөрес һәм үз вакытында булуы өчен вазыйфаи затларның шәхси җаваплылыгы закон таләпләре нигезендә аларның вазыйфаи регламентларында беркетелә.

**Муниципаль хезмәт күрсәтүне тикшереп тору тәртибенә һәм рәвешләренә, шул исәптән гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан да таләпләр**

4.5. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары муниципаль хезмәт күрсәтүнең барышы, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) тәмамлау сроклары турында мәгълүмат алу юлы белән муниципаль хезмәт күрсәтүне контрольдә тотарга хокуклы.

Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары да түбәндәгеләргә хокуклы:

муниципаль хезмәт күрсәтүнең һәркем өчен мөмкинлеген һәм сыйфатын яхшырту буенча кисәтүләр һәм тәкъдимнәр җибәрергә;

әлеге Административ регламентны бозуларны бетерү чаралары турында тәкъдимнәр кертергә.

4.6. Вәкаләтле органның вазыйфаи затлары хокук бозуларны туктату буенча чаралар күрә, хокук бозуларга китерә торган сәбәпләрне һәм шартларны бетерә.

Гражданнарның, аларның берләшмәләренең һәм оешмаларының кисәтүләрен һәм тәкъдимнәрен карау нәтиҗәләре турындагы мәгълүмат әлеге кисәтүләрне һәм тәкъдимнәрне җибәргән затларга җиткерелә.

## V. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт (муниципаль) хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә шикаять белдерүнең судка кадәр (судтан тыш) тәртибе

5.1. Гариза бирүче Вәкаләтле органның, Вәкаләтле органның вазыйфаи затларының, дәүләт (муниципаль) хезмәткәрләренең, күпфункцияле үзәкнең, шулай ук күпфункцияле үзәк хезмәткәренең муниципаль хезмәт күрсәткәндәге

карарларына һәм (яисә) гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) тәртиптә шикаять бирергә хокуклы (алга таба – шикаять).

**Гариза бирүченең судка кадәр (судтан тыш) тәртиптә шикаяте җибәрелергә мөмкин булган җирле үзидарә органнары, шикаятьләрне карап тикшерүгә вәкаләтле оешмалар һәм вәкаләтле затлар**

5.2. Гариза бирүче судка кадәр (судтан тыш) тәртиптә шикаять белән язма рәвештә кәгазьдә яки электрон рәвештә мөрәҗәгать итә ала: Вәкаләтле органга – Вәкаләтле органның структур бүлекчәсенең вазыйфаи затының, җитәкчесенең карарына һәм (яисә) гамәлләренә (гамәл кылмавына), Вәкаләтле органның, Вәкаләтле орган җитәкчесенең карарына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) ; югары органга – Вәкаләтле органның структур бүлекчәсенең вазыйфаи затының, җитәкчесенең карарына һәм (яисә) гамәлләренә (гамәл кылмавына); күпфункцияле үзәк җитәкчесенә – күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына); күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючыга – күпфункцияле үзәкнең карарына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына).

Вәкаләтле органда, күпфункцияле үзәктә, күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючыда шикаятьләрне карап тикшерүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар билгеләнә.

**Гариза бирүчеләргә шикаять бирү һәм карау тәртибе турында, шул исәптәнЕПГУ һәм/яки РПГУ дан файдаланып хәбәр итү ысуллары**

5.3. Шикаятьне бирү һәм карау тәртибе турындагы мәгълүмат муниципаль хезмәт күрсәтү урыннарында мәгълүмат стендларында, Вәкаләтле орган, ЕПГУ һәм/ яки РПГУ сайтында урнаштырыла, шулай ук телефон аша һәм (яки) шәхсән кабул иткәндә телдән бирелә яисә гариза бирүче (вәкил) күрсәткән адрес буенча почта аша җибәрелә.

**Муниципаль хезмәт күрсәтү барышында кабул ителгән гамәлләргә (гамәл кылмауга) һәм (яки) карарларга судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибен җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеге**

5.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүче Вәкаләтле органның, шулай ук аның вазыйфаи затларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе түбәндәгеләр белән җайга салына: 210-ФЗ номерлы федераль закон;

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә кылынган карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2012 елның 20 ноябрендәге 1198 номерлы consultantplus://offline/ref=A397FE100A04CF436DCCCECBCB31C68B42BE200191B

8B806F655A1EE54601F0A8CDCC862B6B13B1233FA6C374EFDx9G Россия Федерациясе Хөкүмәте карары.

## VI. Күпфункцияле үзәкләрдә административ процедураларны (гамәлләрне) үтәү үзенчәлекләре

### Күпфункцияле үзәкләр тарафыннан башкарыла торган дәүләт (муниципаль) хезмәт күрсәткәндә административ процедураларның (гамәлләрнең) тулы исемлеге

6.1 Күпфункцияле үзәк түбәндәгеләрне башкара:

6.1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен КФҮ яисә КФҮнең читтәге эш урыны аша документлар кабул итү.

6.1.2. Гариза бирүче (гариза бирүче вәкиле) шәхсән муниципаль хезмәте күрсәтү турында сорату белән КФҮгә мөрәҗәгать итә һәм Регламентның 2.5 пункты нигезендә документлар тапшыра.

6.1.3. Гаризаларны кабул итүче КФҮ хезмәткәре түбәндәгеләрне башкара:

мөрәҗәгать предметын билгели;

документлар бирүче затның вәкаләтләрен тикшерә;

документларның Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килү-килмәвен тикшерә;

КФҮнең автоматлаштырылган мәгълүмати системасында гаризаның электрон формасын тутыра;

кәгазь чыганакта Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырганда, тапшырылган документларны сканерлый;

КФҮнең автоматлаштырылган мәгълүмати системасыннан гаризаны кәгазьдә чыгартып ала;

гариза бирүчегә тикшерү һәм имза салу өчен тапшыра;

имза салганнан соң, КФҮнең автоматлаштырылган мәгълүмати системасында имзаланган гаризаны сканерлый;

КФҮнең автоматлаштырылган мәгълүмат системасына электрон формада тапшырылган документларны яки сканерланган документларның электрон образларын урнаштыра, электрон эш формалаштыра;

имза салынган гаризаны һәм кәгазь документларның төп нөсхәләрен кире кайтара;

гариза бирүчегә документларны кабул итү турында расписка бирә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: җибәрергә әзер гариза һәм документлар пакеты.

6.2. КФҮ хезмәткәре гариза бирүчедән кабул ителгән документлар пакетын Вәкаләтле органга электрон формада (электрон эшләр пакетлары составында) гариза бирүче КФҮ структур бүлекчәсенә мөрәҗәгать иткән көннән алып бер эш көне эчендә җибәрә.

- кәгазьдә (документларның төп нөсхәләрен мәҗбүри бирү кирәк булган очракта) – гариза бирүче КФҮнең структур бүлекчәсенә мөрәҗәгать иткән көннән алып өч эш көне эчендә.

Процедураларның нәтиҗәсе: электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә Вәкаләтле органга җибәрелгән гариза һәм документлар пакеты (электрон эш).

6.3. Вәкаләтле орган тарафыннан КФҮ аша кергән документлар комплектын карап тикшерү.

6.3.1. Административ процедураны үтәүне башлауның нигезе булып муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм башка документлар килү тора.

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи зат (хезмәткәр) – АИС ЭДС инженеры (алга таба – Вәкаләтле хезмәткәр).

Вәкаләтле хезмәткәр, документлар карап тикшерүгә кергәннән соң, түбәндәгеләрне башкара:

а) документларның күчермәләрен һәм документлар реестрын КФҮдән электрон рәвештә (электрон эшләр пакетлары составында) тапшырган очракта документлар реестрын тапшырылган документлар белән тикшерә;

б) кергән электрон эшләрне, шул исәптән гариза бирүче тарафыннан электрон рәвештә бирелгән документларны һәм документларның электрон образларын өйрәнә;

в) документларның комплектлылыгын, электрон үрнәкләренең укылышын тикшерә;

г) Гариза бирүченең гаризасыннан мәгълүматларны АИС ЭДСка кертә, АИС ЭДСта гаризага «Теркәлгән» статусын бирә, бу Бердәм порталда, Республика порталында Шәхси кабинетта чагылдырыла.

6.3.2. Регламентның 2.7. пунктында каралган нигезләр булганда, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул итә;

Документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар, баш тарту сәбәбен күрсәтеп (муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре мондый документларга куелган таләпләрне бозуга бәйле булган очракта, документларны кабул итүдән баш тарту нигезләрендә тапшырылмаган, дөрес булмаган һәм (яки) каршылыклы белешмәләрне үз эченә алган, куелган таләпләрне бозып рәсмиләштерелгән документларның (мәгълүматлар, белешмәләрнең) атамасы турында мәгълүмат булырга тиеш), Регламентка 5, 6 нчы кушымта нигезендә рәсмиләштерелә, электрон документ әйләнеше системасында теркәлә һәм «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәгариф идарәсе» муниципаль учреждениесенең вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза кулланып имзалана, КФҮгә һәм Бердәм порталда, Республика порталында гариза бирүченең шәхси кабинетына гариза кергән көннән бер эш көненнән дә соңга калмыйча җибәрелә

Әгәр көчәйтелгән квалификацияле электрон имзаны тикшерү нәтиҗәсендә аның чынлык шартларының үтәлмәве ачыкланса, хәбәрнамәдә аны кабул итү өчен

нигез булып тора торган 63-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясы пунктлары булырга тиеш

6.3.3. Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар карау өчен гариза кергән датадан алып бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: баланы исәпкә кую – АИС ЭДСта гаризага «Теркәлгән» статусын бирү яки документларны кабул итүдән баш тарту турында хәбәрнамә.

1 нче кушымта

**Электрон рәвештә муниципаль хезмәт күрсәтүнең (исәпкә куюның) арадаш нәтиҗәсе турында хәбәрнамә формасы**

Мәгълүмат статусы: ***Гариза каралды***

Мәгълүмат статусына аңлатма:
«***Сезнең гариза каралды. Гаризаның индивидуаль номеры ________________. Сайланган белем бирү оешмасына _ _ _ _ _ _ _ (гаризада күрсәтелгән кирәкле кабул итү датасы күрсәтелә) соң юллама көтегез.»***

2 нче кушымта

**Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирү турында карар формасы (кәгазь формада)**

«Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты Мәгариф идарәсе» муниципаль учреждениесе

Кемгә: ___________________________________

**Исәпкә кую өлешендә «Мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм җибәрү» муниципаль хезмәте күрсәтү турында**
КАРАР

дата ________________ № _______________

Сезнең _____________ ______________ номерлы гаризаны һәм аңа беркетелгән документларны карап, «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты Мәгариф идарәсе» муниципаль учреждениесе вәкаләтле органы тарафыннан

___________________________________________________________________________
*вәкаләтле орган исеме*

карар кабул ителде: *(баланың ФИА тулысынча)* муниципаль белем бирү оешмасында урын бирүгә мохтаҗ буларак/ *(гаризада күрсәтелгән параметрларны санап чыгарга)* исәпкә куярга.

________________________________
*Хезмәткәрнең вазыйфасы һәм ФИА*

3 нче кушымта

**Электрон формада муниципаль хезмәт күрсәтү (муниципаль белем бирү оешмасына юллама) турында хәбәрнамә формасы**

Мәгълүмат статусы: ***Мәктәпкәчә белем бирү оешмасына җибәрелгән.***

Мәгълүмат статусына аңлатма:

***«Сезгә _____________ (белем бирү оешмасының исеме, төркем турында мәгълүмат күрсәтелә) _________________________ нигезендә (баланы мәктәпкәчә белем бирү оешмасына җибәрү турында документ реквизитлары күрсәтелә ) урын бирелде»***

***Сезгә ____________ (гамәлне үтәү вакытын күрсәтеп, статусны күрсәткәннән соң, гариза бирүченең гамәлләре тәртибе тасвирлана) кирәк».***

4 нче кушымта

**Муниципаль хезмәт күрсәтү турында карар формасы**
**(кәгазь формада)**

«Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты Мәгариф идарәсе» муниципаль учреждениесе

кемгә: ____________________________________

**Муниципаль белем бирү оешмасына җибәрү өлешендә «Мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм җибәрү» муниципаль хезмәте күрсәтү турында КАРАР (кәгазь формада)**

дата _____________________________ № ________

Сезгә _____________ *(мәктәпкәчә белем бирү оешмасының исеме күрсәтелә),* төркемдә *(компенсация һәм катнаш юнәлешле төркемнәр өчен төрен һәм сәламәтләндерү төркемнәре өчен профилен күрсәтеп, юнәлеше, төркемнең яшь күрсәткече),* булу режимы белән *(баланың төркемдә булу режимы күрсәтелә)* белем бирү программасы буенча уку өчен *(белем бирү программасының исеме һәм юнәлеше күрсәтелә (булганда)),* _____ телендә *(тиешле белем бирү теле күрсәтелә)* /карау һәм тәрбияләүне тормышка ашыру өчен __________________ *нигезендә (баланы мәктәпкәчә белем бирү оешмасына җибәрү турында документ реквизитлары күрсәтелә) урын бирелде*.

Сезгә, баланы кабул итүне раслау өчен, юллама турында беркетмә бастырылганнан соң 30 көн эчендә мәктәпкәчә учреждениегә мөрәҗәгать итәргә кирәк булачак.

*Хезмәткәрнең вазыйфасы һәм ФИА*

5 нче кушымта

**Электрон рәвештә муниципаль хезмәт күрсәтүнең (исәпкә куюның) арадаш нәтиҗәсен бирүдән баш тарту турында хәбәрнамә формасы**

Мәгълүмат статусы: ***Хезмәт күрсәтүдән баш тартылды***

Мәгълүмат статусына аңлатма:

***«Сезгә агымдагы гариза буенча хезмәт күрсәтүдән _________________ сәбәбе буенча (гариза буенча тискәре карар кабул ителүнең сәбәбе күрсәтелә) баш тартылды.***

***Сезгә ____________ (гариза буенча уңай нәтиҗә алу өчен, гариза бирүче башкарырга тиешле гамәлләр тәртибе күрсәтелә) кирәк.»***

6 нчы кушымта

**Муниципаль хезмәт күрсәтүнең арадаш нәтиҗәсен бирүдән баш тарту турында карар формасы (кәгазь формада)**

«Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты Мәгариф идарәсе» муниципаль учреждениесе

кемгә: ____________________________________

**Исәпкә кую өлешендә «Мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм җибәрү» муниципаль хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында**
**КАРАР**

дата ____________________________ № ______________

Сезгә агымдагы гариза буенча хезмәт күрсәтүдән __________________ сәбәбе буенча (*гариза буенча тискәре карар кабул ителүнең сәбәбе күрсәтелә)* баш тартылды.

Сезгә ____________ *(гариза буенча уңай нәтиҗә алу өчен, гариза бирүче башкарырга тиешле гамәлләр тәртибе күрсәтелә) кирәк.*

____________________________________

*Карар кабул иткән хезмәткәрнең вазыйфасы һәм ФИА*

7 нче кушымта

## Электрон рәвештә муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза формасы

____________________________________________

____________________________________________

*(гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), шәхесне раслаучы документ мәгълүматлары, элемтә өчен телефон, почта адресы, электрон почта адресы)*

### Электрон рәвештә муниципаль хезмәт күрсәтү турында ГАРИЗА

<table>
<tr><td>/б<br>№</td><td>Сораулар исемлеге</td><td colspan="2">Җаваплар</td></tr>
<tr><td></td><td>Сез баланың ата-анасымы яки законлы вәкилеме</td><td>Ата-ана</td><td>Законлы вәкил</td></tr>
<tr><td colspan="4">Кулланучының ЕСИАдагы профиленнән түбәндәге мәгълүматлар автомат рәвештә тутырыла:<br>фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта);<br>паспорт мәгълүматлары (сериясе, номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән);<br>ЗАКОНЛЫ ВӘКИЛ булса, электрон рәвештә өстәмә бала хокукларын тапшыруны раслаучы документ(-лар) бирелергә мөмкин.<br>Өстәмә рәвештә ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) элемтә өчен мәгълүматлары (телефон, электрон почта адресы (булганда)) бирелә.</td></tr>
<tr><td></td><td colspan="3">Хезмәт күрсәтү турында гариза бирелгән баланың шәхси мәгълүматлары:<br>фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта);<br>туган көне;<br>бала туу турындагы таныклыкның яисә баланың шәхесен раслый торган башка документның реквизитлары<br>яшәү урыны адресы<br>Гариза бирүченең ЕСИАдагы профилендә бала турында мәгълүматлар булганда, мәгълүматлар автоматик рәвештә тутырыла</td></tr>
<tr><td></td><td colspan="3">Кабул итүнең теләгән параметрлары:<br>Кабул итүнең теләгән датасы:<br>белем биүр теле (исемлектән сайлау);<br>баланың төркемдә булу режимы (исемлектән сайлау);<br>төркемнең юнәлеше (исемлектән сайлау);<br>Компенсацияләү төркеме төре (компенсацияләү юнәлеше төркемнәрен сайлаганда исемлектән сайлау);<br>Адаптацияләнгән программа буенча укыту ихтыяҗын раслаучы документ реквизитлары (булганда);<br>Сәламәтләндерү төркеме профиле (сәламәтләндерү юнәлеше төркемнәрен сайлаганда исемлектән сайлау);<br>Сәламәтләндерү төркеменә булган ихтыяҗны раслаучы документ реквизитлары (булган очракта).</td></tr>
</table>

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Сәламәтләндерү яисә компенсацияләү төркемен сайлаган очракта, өстәмә рәвештә, биргән оешманың көчәйтелгән квалификацияле имзасы белән расланган тиешле документ, психология-медицина-педагогика комиссиясе бәяләмәсе реквизитлары (кирәк булса) электрон рәвештә бирелергә мөмкин. Өстәмә рәвештә, аны биргән оешманың көчәйтелгән квалификацияле имзасы белән расланган тиешле документ электрон рәвештә тапшырылырга мөмкин; кабул итү өчен белем бирү оешмалары (сайлап алу буенча әлеге административ регламентка кушымта нигезендә билгеле бер белем бирү оешмаларына территорияләрне беркетү буенча) | | |
| | *Кабул итү өчен сайланган мәктәпкәчә белем бирү оешмалары исемлеге* | *килешүләр, шул исәптән дәүләт-хосусый, муниципаль-хосусый партнерлык турында килешүләр кысаларында, сайланган мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының өстенлеген күрсәтеп, муниципаль берәмлектә баланың яшәү адресына кертелгән муниципаль белем бирү оешмалары исемлегеннән, шулай ук башка оешмалардан (исемлек төбәк мәгълүмат системаларында формалаша) сайлау; сайлап алырга мөмкин булган мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының максималь саны – өч.* | |
| | *Сайланган мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында урыннар булмаса, кабул итү өчен сайланган мәктәпкәчә белем бирү оешмалары исемлегеннән тыш башка мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына юлламага ризалык* | *бинар тамга «Әйе/Юк», килешү буенча – «Юк»* | |
| | *Гомуми үсеш төркеменә ризалык* | *«Әйе/Юк» бинар билгесе гомуми үсеш юнәлеше булмаган төркем сайлаганда тутырылырга мөмкин, килешү буенча – «Юк»* | |
| | *Карау һәм тәрбияләү төркеменә ризалык* | *бинар тамга «Әйе/Юк», килешү буенча – «Юк»* | |
| | *Кыска вакытлы булу режимына ризалык* | *бинар тамга «Әйе/Юк», килешү буенча – «Юк», көнгә 5 сәгатьтән артык режимнарны сайлаганда тутырырга мөмкин* | |
| | *Тулы көн төркеменә ризалык* | *бинар тамга «Әйе/Юк», килешү буенча – «Юк», тулы көннән аермалы булган режим буенча төркем сайлаганда тутырыла* | |
| | Кабул итү өчен сайланган белем бирү оешмаларында укучы башка балаларыгыз (урын кирәк булган балагызның абый/энесе(-ләре) яисә апа/сеңлесе(-ләре) бармы? | *Әйе* | *Юк* |
| Әгәр дә ӘЙЕ икән, аларның ФИА ны һәм ул (алар) белем ала торган оешманың | | | |

<table>
<tr><td colspan="4">исемен күрсәтегез. ЮК икән, алдагы 5 нче адымга күчегез</td></tr>
<tr><td></td><td>Сезнең махсус ярдәм чараларына хокукыгыз (чираттан тыш яки беренче чиратта язылу хокукы) бармы</td><td>Әйе</td><td>Юк</td></tr>
<tr><td colspan="4">Өстәмә рәвештә, аны биргән оешманың квалификацияле имзасы белән расланган тиешле документ электрон рәвештә тапшырылырга мөмкин.</td></tr>
</table>

8 нче кушымта

**Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза формалары**

«Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәгариф идарәсе» муниципаль учреждениесе башлыгына
___________________________________________
___________________________________________
законлы вәкилнең яки ышанычлы затның ФИА (соңгысы – булган очракта)
яшәү (теркәлү) адресы :
___________________________________________
___________________________________________
Чын яшәү адресы
___________________________________________
___________________________________________
паспорт: сериясе _ _ _ _ _ _ _ _ _ номеры
__________________
бирелгән: «____» ___________________________
___________________________________________
Электрон почта адресы _________________________
тел. _______________________________________

Балалар бакчасына исәпкә кую турында

ГАРИЗА

___________________________________________________________________________
(гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)

Статусы _____________________________________________________________________

(ата-ана (законлы вәкил))

Муниципаль белем бирү оешмасына мохтаҗ буларак исәпкә куюыгызны, шулай ук укуга җибәрүегезне сорыйм
___________________________________________________________________________
(оешманың исеме)

Мәктәпкәчә белем бирү оешмасына кабул итүнең кирәкле датасы
___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
(баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), туу датасы)

Бала туу турында таныклык ___________________________________________________
___________________________________________________________________________,
(сериясе, номеры, бирү датасы)

яшәү адресы: ___________________________________________;
___________________________________________________________________________

Тәрбияләү һәм укыту теле, юнәлеше______________________________________________

Булу вакыты ___________________________________________________________________

- Психологик-медик-педагогик комиссия реквизитлары (булганда);
___________________________________________________________________________

Мәктәпкәчә белем бирү оешмасына чираттан тыш, беренчел, өстенлекле урнашу хокукы булу (булса)
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
(нигез, документлар беркетелә)

Урнаштыруның башка вариантларын (өстенлек тәртибендә) тәкъдим итәргә
1.__________________________________________________________________________
2.__________________________________________________________________________

<u>Гаризага түбәндәге документларны теркәп бирәм:</u>
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________

<u>Дөрес булмаган мәгълүматлар биргән өчен җаваплылык турында кисәтү ясалды</u> ________

______________ ______________
(дата) (имза)

9 нчы кушымта

**Хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар формасы**

«Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе

кемгә: ___________________________________

**«Мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм җибәрү»** муниципаль хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында КАРАР

дата ____________ № ____________

